# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлегенең Монай торак пунктында гражданнар җыены нәтиәләре турында

06.04.2024 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы,
Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы « Монай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгының 2024 елның 27 мартындагы 1 номерлы 2023 елның 16 ноябрендәге 1 номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче Монай авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында", 2023 елның 16 ноябрендәге 2 номерлы "
2024 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлегенең Монай авылында гражданнарның үзара салымнарын кертү турында" гражданнар җыеннары карарларына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында карары белән 2024 елның 6 апрелендә узган гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде. Җыенда 2023 елның 16 ноябрендәге 1 номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче Монай авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында", 2023 елның 16 ноябрендәге 2 номерлы " 2024 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлегенең Монай авылында гражданнарның үзара салымнарын кертү турында" гражданнар җыеннары карарларына үзгәрешләр кертү мәсьәләсенә сез ризамы” дигән сорау каралды һәм чаралар түбәндәгечә бәян ителде:

«1) Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (поселок эчендәге юлларны ремонтлау (Төзүчеләр, Монтажчылар урамындагы чокырлы юл япмасын ремонтлау, вак таш сатып алу));

2) су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итү (Монай торак пунктында чистарту корылмалары өчен 2 данә суырту насослары сатып алу).

3) Тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (Монай торак пунктында урам яктырткычларын сатып алу).

4) торак пункт территориясен төзекләндерү, каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү (контейнер мәйданчыгы урнаштыру һәм күпфатирлы йортлар өчен контейнерлар сатып алу)?»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмәгә ярашлы: сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 360 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны - 184 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«риза» - гражданнар җыенының 184 катнашучысы тавыш бирә;
«каршы» - җыенның 0 катнашучысы тавыш бирә.
Бу нигездә, гражданнар җыенын:

1. Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлегенең Монай торак пунктында гражданнар җыены узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга

2. 2023 елның 16 ноябрендәге 1 номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче Монай авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында", 2023 елның 16 ноябрендәге 2 номерлы " 2024 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлегенең Монай авылында гражданнарның үзара салымнарын кертү турында" гражданнар җыеннары карарларына үзгәрешләр кертү мәсьәләсенә сез ризамы” дигән сорау каралган һәм чараларны түбәндәгечә бәян итеп кабул ителгән дип санарга.

«1) Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (поселок эчендәге юлларны ремонтлау (Төзүчеләр, Монтажчылар урамындагы чокырлы юл япмасын ремонтлау, вак таш сатып алу));

2) су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итү (Монай торак пунктында чистарту корылмалары өчен 2 данә суырту насослары сатып алу).

3) Тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элементләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (Монай торак пунктында урам яктырткычларын сатып алу).

4) торак пункт территориясен төзекләндерү, каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү (контейнер мәйданчыгы урнаштыру һәм күпфатирлы йортлар өчен контейнерлар сатып алу)?»

3. Әлеге карарны карар кабул ителгән көннән соң 10 көн эчендә мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында. www mendsleevsk.tatarstan.ru “Монай авыл җирлеге” бүлегендә бастырып чыгарырга

4. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлеге башлыгына әлеге карарны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Менделеевск муниципаль районы
Монай авыл җирлеге башлыгы ________________ Р.М.Кириллов
(имза) (имзаның аңлатмасы)